КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 сентябрь г.Казань № 1110

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны (карарга теркәлә);

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан бер балага 51,9 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 5 сентябрь, 961 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 05 сентябрь, 961 нче карары белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2023 ел, 17 март, 264 нче.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 8 сентябрь, 1110 нчы
карары белән расланды

## 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Т/с | Балалар һәм яшьләр ялын оештыру формасы | Норматив чыгымнар, бер көнгә бер кешегә койка урынына, сум |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр яны ял лагерендагы смена | 1 132,27 |
| 2. | Шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 1 102,44 |
| 3. | Палатка тибындагы лагерьдагы смена | 1 407,36 |
| 4. | Мәгариф оешмалары тарафыннан көндез оештырылган лагерьда смена,<br>хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 244,27 |
| 5. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 227,78 |
| 6. | Шифаханә-курорт оешмаларындагы смена | 1 563,0 |
| 7. | Кара диңгез яры буендагы шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 2 616,79 |

___________________________